Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

№2 5.02. 2016 ел

**Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге территориясендә 2016 елга наркотикларга каршы чаралар планын раслау турында**

«Россия Федерациясенең 2020 елга кадәр Дәүләт наркотикларга каршы сәясәте стратегиясен раслау турында» Россия Федерациясе Президентының 09.06.2010 № 690 Указы нигезендә, «наркотикларның, психотроп матдәләрнең законсыз әйләнешенә каршы тору буенча өстәмә чаралар турында» Россия Федерациясе Президентының 09.06.2010 № 690 Указы нигезендә, наркомания таралу куркынычын киметү максатларында, Россия Федерациясе Президентының 2016 елга чаралар планы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге башкарма комитеты сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга һәм наркотиклар куллануны профилактикалауга юнәлдерелгән

Карар итә:

1.Иске Кыязлы авыл җирлеге территориясендә 2016 елга наркотикларга каршы чаралар планын расларга (1, 2 нче кушымта).

2.Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының мәгълүмати стендларында һәм рәсми сайтында бастырып чыгарырга: http://aksubaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам

Иске Кыязлы авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: И. М. Заһидуллин

Кушымта №1

Иске Кыязлы авыл җирлеге
башкарма комитеты карарына
№2 5.02. 2016 ел

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге башкарма комитеты каршындагы наркотикларга каршы комиссия составы**

Комиссия рәисе: Заһидуллин Илшат Минсабир улы, Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы

Комиссия секретаре: Гыйматова Гөлия Әхсән кызы, Иске Кыязлы авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары

Комиссия әгъзалары: Сафин Илсур Минсәлих улы, Россия Эчке эшләр министрлыгының Аксубай районы буенча участок инспекторы

Мугинов Искәндәр Срурдин улы, Иске Кыязлы урта мәктәбе укытучысы

Якупова Назия Яхиевна, Иске Кыязлы ФАП мөдире

Кушымта №2
Иске Кыязлы авыл җирлеге
башкарма комитеты карарына
№2 5.02. 2016 ел

**2016 елга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге территориясендә наркотикларга каршы чаралар планы**

Программаның төп чаралары булып:

- оештыру чаралары;
- наркоманияне профилактикалау системасы учреждениеләре һәм оешмалары эшчәнлеге;
- наркотиклар һәм психотроп матдәләрне дөрес кулланмауның тискәре нәтиҗәләрен профилактикалау;
- наркоманиягә каршы тору системасы учреждениеләренең матди-техник базасын камилләштерү;
- эшчәнлекне мәгълүмат белән тәэмин итү

| № п\п | Эчтәлек | Башкару | Үтәлү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1. | Наркотикларга каршы комиссия утырышларын үткәрү | АНК | кварталга 1 тапкыр |
| 2. | Мәдәни-массакүләм һәм ял итү чаралары уздырылган урыннарда наркотикларның таралу фактлары турында мәгълүмат җыю, гомумиләштерү һәм анализлау. | АНК | даими |
| 3. | Китапханә, мәктәп базасында наркомания, алкоголизм, тәмәке тарту һәм ВИЧ-инфекция проблемалары буенча мәгълүмат банкын булдыру һәм саклау | АНК | Даими |
| 4. | Тар профильле белгечләрне (психолог, нарколог һ. б.) җәлеп итеп, авыр тормыш хәленә эләккән яшүсмерләргә консультацияләр бирү | АНК,мәктәп | Кирәк очракта |
| 5. | Яшүсмерләрнең кеше сәламәтлегенә тәмәке тарту, алкоголь, наркомания, ВИЧ-инфекциянең зарарлы йогынтысы турында мәгълүматлы булуларын мониторинглау. | Мәктәп, китапханә | даими |
| 6. | Авыл китапханәсендә наркоманияне профилактикалау буенча чаралар үткәрү (мәгълүмат стендлары, укучылар конференцияләре). | китапханә | Сентябрь, декабрь |
| 7. | Наркомания һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча айлык үткәрү. | Авыл җирлеге башкарма комитеты,АНК, мәктәп | Октябрь |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8. | "Музыка-әйе! Наркотиклар юк!» " акция-концертын оештыру һәм үткәрү | СДК, мәктәп | Ноябрь |
| 9. | Наркотиклы үсемлекләрне юк итү буенча рейдлар үткәрү. | АНК, РФ Эчке эшләр министрлыгының Аксубай районы УУП Участок вәкаләтлесе | Октябрь |
| 10. | Алкогольле продукция һәм сыра сату белән шөгыльләнүче сәүдә нокталары буенча рейдлар үткәрү. | АНК, РФ Эчке эшләр министрлыгының Аксубай районы УУП (полиция) | Ай саен |
| 11. | Кичке вакытта дискотекаларны, яшьләр массакүләм чараларын тикшерү буенча рейдлар үткәрү. | АНК, РФ Эчке эшләр министрлыгының Аксубай районы УУП (полиция) | Ай саен |
| 12. | 2017 елга КХА эш планын раслау. | АНК | Декабрь 2016ел |